| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**17.02.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 306** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 17 сентябрендәге 1936 номерлы карары белән расланган, агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыркуга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын актуальләштерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 28 мартындагы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 437 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 17 сентябрендәге 1936 номерлы (2016 елның 22 июлендәге 1924 номерлы, 2018 елның 23 октябрендәге 2157 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган, агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыркуга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, түбәндәгеләрне өстәп, үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 графада «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» ндәге 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктчаны:
«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычның, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, булмавы турында белешмә».

1.2. 2 графада «Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге» ндәге 2.8 пунктына

түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчаны өстәргә:

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу».

1.3 3.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Департамент белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәгеләрне бирү турындагы соратуларны җибәрә:

1) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүмат булган);

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның, авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклардан тыш, булмавы турында.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорату»

1.4. Административ регламентның 1 нче кушымтасында соңгы абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «Сорату булганда скан аша чыккан документларның төп нөсхәләрен бирергә үземә йөкләмә алам. 2006 елның 27 июлендәге «Шәхси мәгълүматлар турында» 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системага салуга, туплауга, таратуга (шул исәптән тапшыруга) һ.б.) ризалыгымны бирәм».

2. Әлеге карарны ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы З.З. Хажиевка «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3..Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев